A.T.S.S.C. Qazan LENIN isem.
ELKS MASSA KITAPXANESE TEP KITAP SAQLAY BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ
им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань
Уг-к-27

ЯКШӘМБЕ
10 МАРТ
1940 ел
№ 57 (5857)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ВКП(б) ның өлкә конференциясе

Бүген ВКП(б) ның Татарстан оешмасының өлкә конференциясе ачыла. Бу конференция гаять зур политик әһәмияткә ия булган дата белән, ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды ачылуга бер ел тулу көне белән бергә туры килә.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды бөек илебездә сыйныфсыз социалистик җәмгыять төзүне тәмамлау һәм социализмнан коммунизмга тезмәле рәвештә күчүнең программасын бирде. Бу съездда ясаган докладында иптәш Сталин партиябез алдына түбәндәге бурычларны: якындагы 10—15 ел эчендә экономик яктан төп капиталистик илләрне узып китү, ел саен 8 миллиард пот ашлык житештерү, социалистик Конституциябезне тайпылышсыз рәвештә тормышка уткәрү, илнең политик тормышын демократияләштерүне ахрынача тормышка ашыру, партиянең сафларын системалы рәвештә яхшырта бару, партия членнарының политик-идея дәрәҗәләрен күтәрү, җитәкче органнарны түбәндәге эшкә якынайту, кадрлар сайлап алу эшен үзәк итү, марксизм-ленинизм идеяләрен пропагандалауны киң итеп куеп, бурычларын куйды һәм башкалар.

Партиянең Татарстан оешмасы ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан куелган бу төп бурычларны тормышка ашыруда шактый уңышларга ирешүе. Казан шәһәрендәге 55 предприятие буенча 1939 нчы елны, 1937 нче елга чагыштырганда, промышленность продукциясен житештерү 18,4 процентка үсте. Вахитов исемендәге Жиркомбинат, Мехкомбинат, Ленин исемендәге күн заводы һ. б. предприятиеләр 1939 нчы елның производство планын срогыннан алда үтәделәр. Отчет чоры—эшчеләр массасының иҗади активлыгы тагын да күтәрелү чоры булды. Партиябезнең XVIII нче съездыннан соң социалистик ярыш тагын да көчәйде, стахановчылык характерына яңа формасы—күп станокларда эшләүгә күчү, күп профессияләрне үзләштерү хәрәкәте туды.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан кабул ителгән яңа устав һәм съезд карарлары партия сафларын Ватаныбызның алдынгы кешеләре исәбенә тагын да үстерүнең көчле этәргече булдылар. Партия сафларына индивидуаль сайлап алу тәртибендә промышленность һәм колхоз производствосының, совет интеллигенциясе алдынгыларыннан отчет чоры эчендә Татарстан партия оешмасы 16.578 кешене кабул итте. Шулай итеп, партия оешмасының составы отчет чоры эчендә 87,9 процентка үсте. Бу—хезмәт ияләре массасының политик активлыгы тагын да үсүнең, Ленин—Сталин партиясе тирәсенә тагын да тыгызрак тупланының һәм, нихәят, партия-политик һәм масса эшләре үсүнең күчтәк билгесе булып тора.

Соңгы еллар кадрларыбызны марксизм-ленинизм теориясе белән коралландыруның көчле үтерелеш чоры булды. Партияле һәм партиясез ун меңнәрчә большевиклар „ВКП(б) тарихының Кыскача курсы"н, Маркс—Энгельс—Ленин—Сталин әсәрләрен үзләштерүгә өйрәнәләр.

Республикабызның колхозларын һәм совхозларын машиналаштыру, чачу мәйданнарын киңәйтү тукталусыз үсә бара, күп санлы яңа кадрлар—тракторчылар, комбайнерлар, механиклар һ. б. тәрбияләп үстерелде. Йөзләрчә колхозлар югары иген уңышы алу өчен, социалистик терлекчелекне үстерү өчен көрәштә алдынгылык үрнәкләрен күрсәттеләр һәм күрсәтәләр. Үткән елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә Татарстаннан 457 колхоз, 6 совхоз һәм 119 терлекчелек фермасының катнашуы һәм былел катнашырга теләүчеләрнең саны тагын да артуы моны ачык күрсәтә.

Отчет чоры эчендә, бигрәк тә XVIII нче съездыннан соң партия оешмаларының эшләре сизелерлек яхшырды. Коммунистларның авангардлык рольләре үсте, политик-идея дәрәҗәләре тагын да күтәрелде һәм масса белән элемтәләре ныгыды. Башлангыч оешмаларда, райкомнарда, горкомнарда булып уткән отчет-сайлау җыелышлары моны бөтен тулылыгы белән күрсәттеләр. Отчет-сайлау җыелышларында большевистик тәнкыйтьнең киң җәелүе, партия оешмаларының практик эшләрендәге житешсезлекләргә тирән анализ ясау, аларны бетерү өчен конкрет тәкъдимнәр кертү—моңа ачык дәлил.

Партиянең Татарстан оешмасы үзенең XXI нче өлкә конференциясенә зур уңышлар белән килә. Шуның белән бергә, партия, профсоюз оешмаларының, совет һәм хуҗалык органнарының эшендә зур гына житешсезлекләр дә яшәп килә әле. Промышленность предприятиеләренең бер өлешендә производство планнарын үтәлмәү, күп кенә колхозларда һәм совхозларда иген уңышларының түбән булуы, терлекчелек планнарын үтәлмәү бу өлкәдәге житешсезлекләрнең зур һәм җидди булуларын күрсәтәләр.

Бу житешсезлекләрнең сәбәбе нәрсәдә? Ул барыннан да элек, хуҗалык наркоматлары (Татнаркомзем, Наркомлегпром, Наркомлес һ. б.) житәкчеләренең партия һәм хөкүмәт тарафыннан куелган бурычларны үтәүгә җавапсыз карауларында, эшкә анализ ясап бармауда, предприятиеләрдәге һәм колхозлардагы житешсезлекләрне вактында күрә белмәүдә, аларны үз вактында бетерү өчен конкрет чаралар күрмәүдә, эшкә сукыр килеш житәкчелек итүдә, Татарстан Совнаркомының бу житешсезлекләрне бетерү чарасын күрү урнына, фактта аларга юл куеп килүендә.

Турыдан-туры әйтергә кирәк, безнең кайбер житәкчеләребез партиянең XVIII нче съезды карарларын һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин күрсәтмәләрен әле һаман да аңлап житкермәгәннәр. Хуҗалык органнары производстводан ерак торалар, конкрет һәм оператив житәкчелек итмиләр. Әгәр шулай булмаса, аппараттагы канцеляриячелек, бюрократик методлар күптән бетерелгән булырлар иде.

Аерым оешмаларда яшәп килә торган мондый зур житешсезлекләр партиянең район һәм шәһәр конференцияләрендә, җыелышларында шактый дәрәҗәдә күрсәтелделәр. Бүген эшкә башлый торган өлкә конференциясенең бурычы—бу житешсезлекләрне һәм аларны тудыручы сәбәпләрне бөтен тулылыгы белән ачып салудан, кемнең кем булуына карамастан тәнкыйть итүдән, житешсезлекләрне бетерү өчен практик чаралар билгеләүдән гыйбарәт.

Һич шик юк ки, коференция делегатлары партия оешмасының эшенә тирән анализ ясарлар, алда торган зур һәм җаваплы бурычларны дөрес хәл итү юлларын билгеләрләр, ВКП(б) ның Татарстан оешмасының житәкче органнарына иң яхшы большевикларны, Ленин—Сталин партиясе эшенә, коммунизм эшенә ахрынача бирелгән һәм үзенең сәләтлелеген эштә күрсәткән коммунистларны сайлап, Татарстан партия оешмасы алдында торган бурычларны уңышлы хәл итүне тәэмин итәрләр.

ИПТӘШ В. М. МОЛОТОВ ИСМЕНӘ СТИПЕНДИЯЛӘР БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА

Иптәш Вячеслав Михайлович Молотовның 50 еллыгын истә калдыру теләге белән, ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы югары уку йортларындагы аеруча күренекле укучылар өчен Молотов исменә стипендияләр билгеләргә карар бирде:

Ленинград индустриаль институтында—аена һәрберсе 400 сумлык 50 стипендия.

В. И. Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетында — аена һәрберсе 400 сумлык 50 стипендия.

В. И. Ленин исемендәге Киров педагогия институтында — аена һәрберсе 400 сумлык 50 стипендия.

Пермь Дәүләт университетында—аена һәрберсе 400 сумлык 50 стипендия.

Пермь медицина институтында—аена һәрберсе 400 сумлык 50 стипендия.

Пермь авыл хуҗалыгы институтында—аена һәрберсе 400 сумлык 50 стипендия.

Лениннең һәм Сталинның турылыклы көрәштәше, ВКП(б) Үзәк Комитетының Политбюро члены, СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары Вячеслав Михайлович Молотовның тууына 50 ел тулуга карата. РӘСЕМДӘ: В. М. Молотов, И. В. Сталин һәм К. Е. Ворошилов иптәшләр (1939 нчы елда алынган рәсем).

ТАСС фото-клишесе.

Кадерле иптәш Молотов!

Сезнең илле еллыгыгыз көнендә Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный Советы Президиумы Сезне—коммунистик партиянең турылыклы улын, эшче һәм крестьяннәрнең социалистик дәүләтенең данлыклы хөкүмәт житәкчесен, Маркс—Энгельс—Ленин—Сталин эше өчен армыйталмый көрәшүчене чын күңелдән котлый.

Үзегезнең илле еллыгыгыз көненә Сез—бөек Ленин—Сталин партиясе тарафыннан тәрбияләнгән көрәшче—данлыклы юлны үттегез. Ленин һәм Сталин житәкчелегендә большевистик оешма сафларында эшләп, Сез, һәр вакытта да Лениннең эзлекле революцион юлы өчен ныклы көрәшүче сыйфатында чыктыгыз. Столыпин реакциясе чорындагы авыр еллар, кулга алынулар һәм сөргеннәр царизмга һәм буржуазиягә каршы көрәштә Сезнең ныклыгыгызны, батырлыгыгызны һәм революционерларча үз-үзегезне аямаучанлыгыгызны какшата алмадылар.

1917 нче елның октябрь көннәрендә, Сез, Лениннең һәм Сталинның якын көрәштәше сыйфатында, капитализм строен штурмлауга житәкчелек итүче штабта булдыгыз, эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең җиңүле кораллы восстаниесен оештыручыларның берсе булдыгыз.

Бөек Октябрь Социалистик Революциясе җиңгәннән соң, Сез дәүләт һәм партия төзелешенең җаваплы тармакларында эшләдегез, совет республикасының җиңүе өчен хезмәт ияләрен көрәшкә оештырдыгыз.

Капиталистик чолганыш агентурасына каршы рәхимсез көрәшнең соңгы елларында—пролетарийлар, хезмәт ияләре Сезне бөек Сталинның якын көрәштәше сыйфатында, социализм өчен көрәштә тайпылышсыз житәкче сыйфатында беләләр.

Марксизм-ленинизмны һәр төрле бозуларга карата сезнең килешмәүчәнлегегез, партиянең төп юлын тормышка ашыруда тайпылышсыз эзлеклелегегез, партия һәм халык дошманнарына каршы көрәштә рәхимсез булуыгыз һәр вакытта да Ленинчел—Сталинчыл партиялелекнең үрнәге булып хезмәт итәр.

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе постында үзегезнең дәүләт эшегездә Сез Ленин—Сталин эпохасындагы партия һәм дәүләт эшлеклесе сыйфатларын бик яхшы итеп бергә куша белү үрнәге булып торасыз.

Сезнең практик житәкчелегегез астында Сталинчыл бишьеллыклар тормышка ашырылды, Совет дәүләтенең экономик һәм оборона куәтен ныгыту буенча гаять зур эш җәелдерелде.

Чиктән тыш катлаулы халыкара мөнасәбәтләр шартларында, икенче империалистик сугыш җәелеп барган шартларда, Сезгә Совет дәүләтенең тышкы политикасына турыдан-туры житәкчелек итү йөкләтелде. Сез бу бурычларны СССР га куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм Советлар Союзы халыкларының тыныч хезмәтен тәэмин итү интересларыннан чыгып уңышлы рәвештә хәл итәсез.

Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный Советы Президиумы, Сезнең социалистик Ватан каршындагы гаять зур хезмәтләрегезне күрсәтеп, Сезгә, Совет Социалистик Республикалар Союзы халыклары файдасына һәм алар бәхете өчен тагын да озак һәм озак еллар яшәвегезне һәм эшләвегезне чын күңелдән тели.

Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный Советы Президиумы.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Киров өлкәсендәге Нолинск шәһәренең һәм Нолинск районының исмен үзгәртү турында

Киров өлкәсендәге Нолинск шәһәре һәм Нолинск районы җәмагат оешмаларының теләген үтәп, Нолинск шәһәре исмен **Молотовский** шәһәре дип һәм Нолинск районы исмен **Молотовский** район дип алмаштырырга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
8 март, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Смолинскидагы хәрби-политик училищегә һәм Горькидагы зенит артиллериясе училищесенә иптәш В. М. Молотов исмен бирү турында

Иптәш В. М. Молотовның илле еллыгын истә калдыру теләге белән,—

1. Смолинскидагы хәрби-политик училищегә һәм
2. Горькидагы зенит артиллериясе училищесенә иптәш Молотов исмен бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
8 март, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Таганрог шәһәрендәге „Красный Гидропресс" заводы исмен иптәш В. М. Молотов исмендәге завод дип алмаштыру турында

„Красный Гидропресс" заводының эшчеләре һәм инженер-техник работниклары коллективының үтенечен канәгатьләндерергә һәм заводның исмен иптәш В. М. Молотов исмендәге завод дип алмаштырырга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль,
8 март, 1940 ел.

РСФСР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫННАН

Кадерле иптәш Молотов!

Сезнең 50 еллыгыгыз көнендә РСФСР Халык Комиссарлары Советы Сезгә, Совет Хөкүмәте башлыгына, бөек Сталинның данлыклы көрәштәшенә һәм турылыклы дустына, эпохабызның күренекле дәүләт эшлеклесенә үзенең большевистик сәламен җибәрә, Сезнең, озак еллар буена сәламәт яшәвегезне һәм гаять зур иҗад эшендә Сезнең уңышлы эшләвегезне тели.

Сезнең тормышыгыз—ныклы хезмәт үрнәге булып һәм халык дошманнарына каршы килешмәүчән көрәш үрнәге булып, бөтен хезмәт иясе кешелек дөньясы бәхте өчен, коммунизм эше өчен көрәш үрнәге булып тора.

Илебезнең тормышындагы гаять әһәмиятле вакыйгалар Сезнең исмегезгә бәйләнгән. Сез—Бөек Октябрь Социалистик Революциясен актив оештыручыларының һәм житәкчеләренең берсе, Совет властен данлыклы иҗад итүчеләрнең берсе, социалистик дәүләтнең күренекле житәкчесе.

Бөтен практик эшегездә, теоретик хезмәтләрегездә, докладларыгызда һәм чыгышларыгызда Сез социалистик төзелешнең эре һәм катлаулы мәсьәләләрен чынчыннан Ленинчә куя һәм хәл итә белү үрнәкләре күрсәттегез.

Гаять зур дәүләт эше тәҗрибәсендә Сез Совет дәүләтен ныгыту һәм аның куәтен көчәйтү буенча, бишьеллык планнарны тормышка ашыру буенча, социалистик культураны үстерү буенча һәм дәүләт аппаратын оештыру һәм ныгыту буенча бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның күрсәтмәләрен тормышка ничек ашырырга кирәклеккә өйрәтәсез.

Советлар иленең тынычлыкны ныгытуга юнәлдерелгән һәм СССР белән яхшы күршеләрчә мөнасәбәткә омтылучыларның барсы белән дә дуслык урнаштыруга юнәлдерелгән тышкы политика өлкәсендәге күренекле вакыйгалар Сезнең исмегезгә бәйләнгән.

ССР Союзы хөкүмәте Сезнең житәкчелегегездә эзлекле рәвештә тынычлык политикасы үткәрә, сугыш уты кабызучыларны фаш итә, Ватаныбызның оборона сәләтен һәм Кызыл Армиянең җимерелмәслек куәтен барлык чаралар белән ныгыта.

Күп миллионлы совет халкы Сезгә, иптәш Молотов, югары бәя бирә һәм Сезне чын күңелдән ярата, дәүләт идарәсе руле Сезнең кулда икәнлеген—бөек Сталинның иң яхшы дустының һәм көрәштәшенең турылыклы һәм ышанычлы кулларында икәнлеген, Ленин—Сталин эпохасының гаять зур дәүләт эшлеклесенең, үзенең тормышы коммунизмның җиңүе өчен армый-талмый көрәштә үтә торган кешенең кулларында икәнлеген белә.

Илебездә коммунизм төзү буенча гаять зур иҗад эшендә Сезгә озак һәм озак еллар буена сәламәтлек һәм уңыш телибез.

Яшәсен җиңелмәслек большевиклар партиясе, Ленин—Сталин партиясе!

Яшәсен бөтен хезмәт иясе кешелек дөньясының юлбашчысы бөек Сталин!

Яшәсен социализм иле хөкүмәтенең башлыгы иптәш Молотов!

РСФСР Халык Комиссарлары Советы.

ССР СОЮЗЫ ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕНӘ—ИПТӘШ ВЯЧЕСЛАВ МИХАЙЛОВИЧ МОЛОТОВКА

Баш Хәрби Совет Кызыл Армия исменнән Сезнең илле еллыгыгыз көнендә Сезгә, Лениннең һәм Сталинның якын көрәштәшенә үзенең кызыл армеецларча сәламен җибәрә һәм кайнар рәвештә котлый.

Ленин һәм Сталин белән берлектә иптәш Молотов, Сез, куәтле большевиклар партиясен төзедегез, алар белән берлектә Сез партияне һәм эшчеләр сыйныфын 1917 нче елның октябрендә җиңүле кораллы восстаниегә һәм пролетариат диктатурасын яулап алуга алып бардыгыз.

Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армияне политик агарту эшләре белән шөгыльләнеп Сез, гражданнар сугышы фронтларында җиңүләрне оештырдыгыз.

Кызыл Армияне төзүнең беренче көннәреннән үк Сез аның иң якын дусты булып әвереләдегез. Совет дәүләте житәкчесе сыйфатында Сезнең Кызыл Армиягә армый-талмый житәкчелек итүегез һәм аның турында Сталинча кайгыртучанлык күрсәтүегез Ватаныбызның дошманнарына каршы сугышларда Кызыл Армиянең ныклыгын һәм какшамаслык куәтен тәэмин иттеләр.

Большевистик партиябезнең һәм социалистик Ватаныбызның дошманнарына карата барлык этапларда да рәхимсез булуыгыз Кызыл Армиянең һәрбер сугышчысы, командиры һәм политработнигы өчен үрнәк булып хезмәт итә.

Илебездә бөек тарихи җиңүләр һәм социалистик дәүләтнең куәтен ныгыту Совет дәүләте житәкчесе булуыгыз сыйфатында Сезнең исмегез белән бәйләнгән.

Совет дәүләте житәкчесе сыйфатында Сезнең приказыгыз буенча, 1939 нчы елның 17 нче сентябрендә Кызыл Армия „Ватан өчен", „Бөек Сталин өчен" дигән лозунглар белән барып, мактанчык ак паннарның өерен тар-мар итте һәм Көнбатыш Украинадагы, Көнбатыш Белоруссиядәге унөч миллион туганнарыбызны азат итте.

Бүгенге көндә Ленинград Хәрби Округының сугышчылары, Ватаныбызның төньяк-көнбатыш чиген саклап һәм империалистик сугыш учагын бетереп, Совет хөкүмәтенең приказы буенча шундый ук көч белән Маннергейм гаскәрләрен тар-мар итәләр.

Иптәш Молотов, Сезнең данлыклы илле еллыгыгыз көнендә, Ватаныбызның хезмәт ияләре файдасына Сезнең озак һәм озак еллар яшәвегезне телибез.

Баш Хәрби Совет.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Әмин Хәлил улы Тынчеров иптәшне Татарстан АССР Совнаркомы Председателе хезмәтеннән азат итү турында

Әмин Хәлил улы Тынчеров иптәшне, аның башка эшкә күчүе уңае белән, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Халык Комиссарлары Советы Председателе хезмәтеннән азат итәргә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе *Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.*
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре өчен *Г. ИШМОРАТОВА.*

Казан, Кремль.
9 март, 1940 ел.

СССР РЕВОЛЮЦИЯ МУЗЕЕНДӘ

СССР Революция музеендә шушы көннәрдә Вячеслав Михайлович Молотовның тормышына һәм революцион эшенә багышланган экспозиция ачылды. Карарга керүчеләр Лениннең һәм Сталинның турылыклы көрәштәше, ялкынлы большевик — иптәш Молотовның образын тудыручы күп сандагы документаль экспонатларны һәм художестволы әсәрләрне тирән кызыксыну белән карыйлар.

„В. М. Молотовның тормышы һәм революцион эше" темасы буенча экскурсияләргә житәкчелек итү өчен экскурсия житәкчеләре группасы билгеләнде. 9 нчы мартта Революция музее залларында 1.000 нән артык кеше булды. Экспозицияне барлыгы 7.000 нән артык кеше карады. (ТАСС).

БОЛЬШЕВИСТИК ПАРТИЯЛЕЛЕК ҮРНӘГЕ

М. И. КАЛИНИН

Безнең революциягә кадәрге әдәбиятыбыз, аның иң яхшы вәкилләре, халыкка иң яхшы хезмәт итү юлларын бик тырышып эзләделәр. Ләкин әйтергә кирәк, хәтта бөек рус язучылары да, буржуаз җәмгыять даирәсеннән һәм аның дөньяга карашыннан читкә чыкмаганлыктан, халыкның изүчеләрне җиңүен тәэмин итәрлек юлларны күрмәделәр, бу юллар өчен көрәшүче кешеләрне дә күрмәделәр.

Совет әдәбияты гаять яхшы шартларда тора. Ул марксизм-ленинизм теориясе белән, пролетар революция тәҗрибәсе белән, социализмны практик төзү белән баетыла. Ниһаять, совет җәмгыяте аңа үзенең әсәрләре өчен матур әдәбият формасында реаль чынбарлыктан уңайлы геройлар эзләп табарга мөмкинлек бирә. Бу яктан алганда совет әдәбиятының уңышлары бәхәссез. Ләкин минемчә, социализм өчен көрәшчеләрнең һәм аны төзүчеләрнең тагын да катлаулырак һәм гомумиләштерелгән типларын тудыруда тагын да алга бару өчен безнең художникларыбызга партия тарихын һәм аның эшлеклеләрен тагын да тирәнрәк өйрәнергә кирәк.

Бүген иптәш Молотовның илле еллыгы һәм партиябез сафларында утыз елдан артыграк эшләве унае белән бу фикерләр ирексездән башка киләләр.

Иптәш Молотовка хәтта чама белән генә, хәтта өстән генә булса да тулы характеристика бирергә мөмкинлегем булмаганлыктан, мин аның үземчә барыннан да бигрәк күзгә бәрелеп тора торган бер генә сыйфатын әйтеп үтәргә телим.

Иптәш Молотов безнең партиябезгә 1906 нчы елны, ягъни Россиядә беренче буржуаз-демократик революция инде асылда кими башлаган чорда керде. Патша хөкүмәте, беренче удардардан айнып, һөҗүмгә күчте һәм илнең төрле шәһәрләрендә һәм районнарында революцияне бастырды. Халык революциясенең тиңдәшсез киң колачыннан патша үзе курыккан кадәр үк курыккан либерал буржуазия хәзер патшаның кочагына ташланды. Ул аның белән нинди генә „конституция“ нигезендә булса да алыш-биреш итәргә хәзер торды. Буржуаз-демократик интеллигенция арасында „Вехи“ идеяләре дип аталган идеяләр, ягъни ренегатлык, революциядән ваз кичү, ягъни „октябристлар буржуазиясенә карата, иске властька карата, гомумән бөтен иске Россиягә карата үзләренең „лакейлык“ хисләрен (һәм шуңа ярашлы рәвештә „лакейлык“ политикаларын) игълан итү“ (Ленин) идеяләре торган саен киңрәк таралды.

Шушы үзгәрешләр нигезендә буржуаз җәмгыятнең барлык катлауларында да революциягә пычрак ташлау, революцион подпольегә нәләт уку һәм марксизмны сүгү „модага“ керә башлады. Шушындый „модный“ настроениеләр социал-демократ интеллигенциянең дә зур өлешен чолгап алдылар. Меньшевиклар, революция бетте дип, яшерен революцион партияне бетерергә һәм „яңартылган“ самодержавие строена яраклашып, патшадан легаль мөмкинлекләрне киңәйтүне сорап, яки, дөресрәге, үтенеп, политиканы легаль оешмалар нигезендә генә алып барырга кирәк дип санадылар. Ә элекке большевикларның бер өлеше, большевистик оешмадан аерылып киткән Богданов һәм башкалар кебек интеллигентлар марксизмның философия нигезләренә ачыктан-ачык ревизия ясый башладылар. „Материализм һәм эмпириокритицизм“ дигән китабында Ленин барлык ревизионистларга һәм марксизмны бозучыларга тиешле ударны бирде.

Димәк, контрреволюция һөҗүм иткәндә, реакция башланганда, контрреволюция үзен инде җиңүче дип хис иткәндә,—шул вакытта иптәш Молотов большевиклар сафларына керде.

Ул башта Казан укучылары арасында эшләп, беренче тапкыр Вологдага сөргенгә җибәрелде. Вологдада аның яшерен эше большевиклар группасы оештырудан башланды. (Монда ул экстерн тәртибендә аттестат алу өчен имтихан бирде, бу аңа 1911 нче елны сөрген срогы тулганнан соң Петербургдагы политехника институтына керергә мөмкинлек бирде).

Ул замандагы барлык шартлар һәм иптәш Молотовның партия эшенең башлануы үзе дә, аның партиягә керүенең яшлеге белән мавыгуы аркасында гына булмаганлыгын, бәлки тулысынча аңлап эшләнгәнлеген һәм бу эшнең аның шуннан соңгы бөтен тормышын һәм политик эшен билгеләгәнлеген ачык күрсәтәләр. Ул иҗтимагый агымга каршы барды, әгәр дә шулай әйтергә яраса, үзенең тормышында һәм эшендә иң кыен, иң авыр юлны сайлап алды. Башка революционерларның практик тормышындагы бик күп санлы мисалларга һәм үзенең политик эшенең башлануына караганда, ул бу юлда үзенә төрмәләргә, сөргеннәргә һәм реакциянең башка төрле җәзалауларына дучар булачагын яхшы күрә ала иде.

Бу юлны ул шуның өчен сайлап алды, чөнки үзенең тирәнтен ышануы буенча аны эшчеләр сыйнфына, халыкка хезмәт итү эшендә иң намуслы, иң нәтиҗәле юл дип санады. Һәм без күрәбез, иптәш Молотовның шуннан соңгы бөтен эше бары тик шушы максатка гына буйсындырылган. Ул үзен бөтенләе белән эшчеләр сыйнфы идеаллары өчен һәм шуның белән бергә—бөтен изелгән халык өчен, хезмәт ияләрен һәр төрле коллыктан һәм изелүдән азат итү өчен көрәшкә, рәхимсез көрәшкә бирде. Ә моның өчен, билгеле, бары тик безнең партиябез генә, Ленин—Сталин партиясе, большевистик партия генә турыдан-туры, эзлекле рәвештә һәм ахрынача көрәште.

Вологдада сөрген срогын тутырганнан соң иптәш Молотов Петербургка күчеп килде. Башкалада яшерен эш алып бару зур колачлы политик эшлеклеләр өчен бик яхшы мәктәп иде. Мәгълүм ки, Петербург революцион көрәш үзәге иде. Питер пролетариаты иң оешкан пролетариат иде. Патша самодержавиесенә һәм капитализмга каршы көрәшкә аның омтылышы бик көчле иде. Петербургда большевиклар партиясенең иң көчле дошманнары бар иде. Мин монда патша охранкасы һәм полициясе органнарын гына түгел, бәлки кара груһлардан алып анархистларга кадәр барлык иҗтимагый-политик оешмаларны күздә тотам. Эшчеләр арасында йогынты ясау өчен бу партияләргә каршы бик каты көрәш алып барылды.

Иптәш Молотов менә шушы политик буталыш эчендә эшләде. Шунда ул большевистик җитәкчелектә чыныкты.

Патша охранкасы иптәш Молотовның эшенә тиешенчә „бәя“ бирде. 1913 нче елның апрелендә ул кулга алынды һәм Петербургдан куылды. Шәһәр читендә урнашып, иптәш Молотов Петербург оешмасында актив эшләвен дәвам иттерде һәм „Правда“ да эшләп, большевизм эшен нык энергия белән яклап килде. Озак та үтми, ул яңадан кулга алынды, ләкин бу юлы эш уңайлы чыкты, ягъни ул элек сөрелгән урнында калдырылды. 1914 нче елның маенда яңадан кулга алына, ләкин бу юлы җәза дәрәҗәсе көчәйтелгән иде. Бөтен дөнья сугышы башлангандa иптәш Молотов яшерен рәвештә Петербургка кайтты һәм шунда ук партиядә җитәкчелек эшенә кушылып, Ленин политикасын эзлекле төстә үткәреп килде.

1916 нчы елның көзендә партия Үзәк Комитеты иптәш Молотовны Үзәк Комитетның Россия бюросына кертә, бу бюрога февраль революциясе алдыннан һәм шул революция вактында партиянең барлык оешмаларына, ә алар аркылы илнең пролетариатына турыдан-туры һәм практик җитәкчелек итүдән гыйбарәт булган җаваплы бурыч йөкләнгән иде.

Иптәш Молотовның революция алдындагы бөтен чор эчендә булган иҗтимагый-политик эшенә кыскача йомгак ясап, мин барыннан да элек һәм бигрәк тә бу эшнең идея ягыннан тирәнлеген, революцион-марксистик эзлеклелеген, Ленин юлын практикада тайпылышсыз үткәрүен, коммунизм өчен көрәштә бер максатка юнәлдерелгән булуын, кыскасы, чын мәгънәсе белән партияле эш икәнлеген әйтергә теләр идем. Ә бу сыйфатны мин революционерның иң төп, иң кыйммәтле сыйфаты дип саныйм. Һәм әйтергә кирәк, бу сыйфат революциягә кадәрге чорда безнең партиябезнең бөтен көрәшендә тирән эз калдырды. Мондый кешеләр: без царизмга каршы уңышлы көрәштек, эшчеләр сыйнфының соңгы максатын тормышка ашыру юлын арчыдык дип горурлык белән әйтә алалар.

В. М. Молотов һәм М. И. Калинин иптәшләр колхозчы ударникларның 2 нче Бөтенсоюз съездында.

Октябрь алдындагы давыллы көннәрдә без иптәш Молотовны Петроград советының төп җитәкчеләреннән берсе һәм Хәрби-Революцион Комитет члены сыйфатында кораллы восстание хәзерләүгә һәм аны үткәрүгә җитәкчелек итүдә күрәбез.

Октябрь кораллы восстаниесе җиңүле төстә төгәлләнү белән үк партия һәм Совет власте җимереклеккә каршы көрәшергә тотындылар. Җиңүне беркетү өчен промышленностьның эшләвен бик аз гына булса да тәэмин итәргә кирәк иде. Менә иптәш Молотов төньяк районы, ягъни Петроград губернасы тирәсендәге бөтен бер губерналар группасы халык хуҗалыгы советының председателе итеп күтәрелә. Монда ул социалистик төзелешкә турыдан-туры җитәкчелек итә башлый, эшчеләр контролен практикада тормышка ашыра һәм промышленностька национализация үткәрә.

Гражданнар сугышы елларында иптәш Молотов партия һәм совет төзелешенең иң әһәмиятле тармакларында эшләп, пролетариат диктатурасын ныгытты.

Партиянең X нчы съездында иптәш Молотов Үзәк Комитет члены итеп сайланды.

Иптәш Молотов 10 ел буена диярлек Партия Үзәк Комитеты секретаре булып эшләде. Аның бу чордагы эше турында язу—илебезнең төзелеш тарихын, Совет властеның ныгуы тарихын, коммунистлар партиясенең барлык дошманнарына каршы, шул исәптән партия эчендәге һәр төрле хыянәтчеләргә һәм сатлыкларга каршы рәхимсез көрәш тарихын язу дигән сүз. Бу эшнең нәтиҗәле булып чыкканлыгын социалистик төзелеш өлкәсендә дә, шулай ук партиянең бердәмлеген ныгыту эшендә дә һәр кемгә мәгълүм булган уңышлар бик яхшы күрсәтәләр.

Ленин һәм Сталин җитәкчелегендә иптәш Молотов Үзәк Комитет һәм Политбюро члены буларак, Үзәк Комитет секретаре буларак үзенең бөтен эшендә марксизм-ленинизм байрагын югары тотты. Ул Ленин һәм Сталин идеяләрен һәм күрсәтмәләрен тайпылышсыз рәвештә тормышка үткәрүче булды. Ә бу, асылда, совет халкына һәм партиягә иң яхшы һәм иң күп файда белән хезмәт итү.

1930 нчы елның декабреннән иптәш Молотов СССР Совнаркомы председателе. Совет хөкүмәте башлыгы сыйфатында эшкә керешкәндә ул үзенең бурычын түбәндәгечә билгеләде: „Мoңа кадәр миңа башлыча партия работнигы сыйфатында эшләргә туры килде. Сезгә белдерәм, иптәшләр, Совнаркомда эшләүгә дә мин партия работнигы сыйфатында, партиянең һәм аның Үзәк Комитетының теләген үткәрүче сыйфатында киләм“.

Иптәш Молотовны якыннан белгән һәрбер кешегә аның бу белдерүне матур сүзләр әйтү өчен генә ясамаганлыгы аңлашылыр. Бу белдерүдәге фикер аның эчке асылын күрсәтә. Иптәш Молотов белән партия бер-берләреннән аерылгысыз.

Совнарком председателе постында ун ел диярлек эшләве чорында иптәш Молотов совет эшенә партиячә, большевикларча юнәлеш биреп, Ленин—Сталин политикасын эзлекле төстә һәм тайпылышсыз үткәреп килде. Иптәш Молотов инициативасы буенча һәм аның җитәкчелегендә кабул ителгән барлык карарларны, аның барлык китапларын, мәкаләләрен, речьләрен, докладларын актарып чыгарга мөмкин,—һәм шунда ук, артык мәшәкатьләнмичә генә, һәрбер кеше аларның марксизм-ленинизм принципларыннан, партия күрсәтмәләреннән килеп чыкканлыгын күрәчәк. Ә менә бу инде Совет дәүләт эшлеклесенең иң кыйммәтле сыйфаты.

Партиянең турылыклы сугышчысы булу—бөек эш. Безнең илебез кичерә торган иң киеккен моментларда иң яхшы кешеләрнең партиягә күпләп агылулары тикмәгә түгел. Фронтта сугыш алдыннан яки берәр куркынычлы заданиене үтәү алдыннан партиясез кешеләрнең үзләрен партиягә язуны, алуны сораулары тикмәгә түгел. Моның тирән мәгънәсе бар.

Иптәш Молотов партиягә, марксизм-ленинизмга турылыклы булу үрнәге булып хезмәт итә. Аның зур һәм кечкенә мәсьәләләрне хәл итүгә якын килүе тирәнтен партиялелек белән сугарылган. Үзенең революцион эшенең башлануыннан алып безнең көннәргә кадәр ул партия өчен көрәштә беренче сафларда тора. Болар барсы да аның марксизм-ленинизмны тирәнтен аңлавын, үзенең дәүләт эшендә аны практик тормышта куллана белүен барыннан да яхшырак күрсәтәләр.

Бүген партия, совет халкы иптәш Молотовның данлыклы исемен, большевистик партиялелек символы сыйфатында, халык интересларына һәм җиңелмәслек Ленин—Сталин байрагына Совет хөкүмәтенең турылыклы булуының билгесе сыйфатында гаять зур канәгатьләнү һәм горурлык хисе белән телгә алалар. Алар аңа кайнар сәлам һәм котлау җибәрәләр. Алар аңа хезмәт ияләренең бәхете өчен, Ватаныбызның чәчәк атуы өчен, коммунизмны яулап алу өчен тагын да күп һәм күп еллар эшләүне чын күңелдән телиләр.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды

ВКП(б) ның XVIII нче съезды партиябезнең һәм бөтен илнең тормышында гаять зур вакыйга булды. Бу съезд, коммунизмның беренче фазасын—социализмны нигездә төзегәннән соң Советлар Союзы сыйныфсыз социалистик җәмгыять төзелешен төгәлләү һәм социализмнан коммунизмга тезем-ле рәвештә күчү полосасына керде дип белдерде.

Иптәш Сталин докладында, Молотов һәм Жданов иптәшләрнең докладларында илебезнең бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмияте булган җиңүләренә—халык хуҗалыгының, культураның һәм хезмәт ияләренең тормыш дәрәҗәсенең гаять дәрәҗәдә үсүенә йомгаклар ясалды һәм коммунизмга таба тагын да алга баруыбызның юллары күрсәтелде. XVII нче съезддан XVIII нче съездга кадәр булган чор илебездә социализм төзелеше тарихында хәл иткеч чор булды: барлык эксплоататор сыйныфлар бетерелде; сыйнфи тигезсезлекне һәм кешенең кешене эксплоатацияләвен, җәмгыятнең эксплоататорларга һәм эксплоатацияләнүчеләргә бүленүен тудыра торган сәбәпләр ок ителде. Безнең җәмгыятебез бер-берсе белән дус булган ике сыйныфтан — эшчеләрдән һәм крестьяннардан, шулай ук совет интеллигенциясеннән тора. Совет халкының мораль-политик бердәмлеге тудырылды. Ике бөек көч—халык һәм коммунизм бергә кушылды.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды илебез алдына якындагы 10—15 ел эчендә төп капиталистик илләрне экономик яктан да куып җитәргә һәм узып китәргә дигән бөек бурычны куйды. Бу, Советлар Союзы дөньяда алдынгы ил, социалистик муллык иле булырга тиеш һәм булыр дигән сүз.

СССР ның төп экономик бурычын хәл итүнең гаять зур әһәмияте бар: коммунизмның югарыгы фазасына күчү, „һәр кемнән сәләтенә карап, һәр кемгә ихтиаҗына карап“ дигән төп коммунистик принципны тормышка ашыру мөмкинлеге шул бурычның уңышлы хәл ителүенә бәйләнгән булачак. „Без төп капиталистик илләрне экономик яктан узып киткән хәлдә генә илебезнең куллану әйберләре белән тулысынча тәэмин ителүенә, бездә продуктларның мул булуына һәм коммунизмның беренче фазасыннан аның икенче фазасына күчү мөмкинлегенә ирешүебезгә исәп тота алабыз“ (И. Сталин. ВКП(б) ның XVIII нче съездында ясаган докладыннан).

Бу бурычны уңышлы хәл итү өчен бездә шартлар бармы?

Әйе, бар. Без промышленностьта һәм авыл хуҗалыгында производство техникасы ягыннан барлык илләрдән алда торабыз. Бездә халыкның техник белеме һәм культурасы гаять дәрәҗәдә үсте, халыкның тормыш дәрәҗәсе бик нык күтәрелә. Халык хуҗалыгын үстерү темплары ягыннан без барлык капиталистик илләрдән алда барабыз. СССР да иң эре һәм иң алдынгы социалистик игенчелек бар. Хуҗалыкның социалистик системасы экономик кризисларны, эшсезлекне белми. Совет халкында һичбер бетмәслек хезмәт геройлыгы чыганаклары, хезмәт җитештерүчәнлеген өзлексез үстерү өчен көчле резервлар бар. Безнең халкыбызга бөек һәм җиңелмәслек Ленин—Сталин партиясе җитәкчелек итә.

СССР ның төп экономик бурычын үтәү буенча эш программасында өченче бишьеллык планга гаять зур әһәмият бирелә. Иптәш Молотов: „Өченче бишьеллык планны үтәү күп яклардан бу бурычның үтәлүен алдан ук хәл итеп куярга тиеш“ диде. Мәсәлән, өченче бишьеллык ахрында СССР ның промышленность продукциясе Германиянең, Италиянең һәм Япониянең—бөтенесенең продукциясеннән артып китәчәк. Машиналар җитештерүдә җан башына туры килә торган сан ягыннан без Европадагы барлык илләрне узып китәчәкбез. Электр энергиясе, чуен, корыч һ. б. җитештерү ягыннан СССР Англиядән, Франциядән һәм Германиядән бик күп алда булачак.

Өченче бишьеллыкта җитәкчелек роле машина төзелеше кулында кала. Ул бөтен халык хуҗалыгын һәм илнең оборонасын техник яктан коралландыруның тагын да күтәрелүен тәэмин итәргә тиеш. Промышленностьның барлык тармаклары һәм беренче чиратта авыр индустрия бик нык үсәчәкләр. Өченче бишьеллыкның соңгы елы өчен СССР ның бөтен промышленность продукциясенең күләме 184 миллиард сумлык итеп билгеләнде. Димәк, икенче бишьеллыкка чагыштырганда үсеш 92 процент.

Өченче бишьеллык планны үтәү нәтиҗәсендә без промышленность продукциясен сугышка кадәргедән 15 тапкыр күбрәк җитештерәчәкбез. Өченче бишьеллыкта продукциянең уртача еллык үсеше 14 процент итеп билгеләнде. Хезмәт җитештерүчәнлеге 65 процент артырга тиеш. 1942 нче елны хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру исәбенә генә дә продукциянең 1937 нче елга чагыштырганда 62 миллиард сумга үсүе тәэмин ителәчәк.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан совет халкы алдына куелган иң әһәмиятле бурыч—хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдән, кешеләрнең аңында капиталистик караш калдыкларын бетерүдән гыйбарәт. Коммунизм төзелеше буенча безнең бөтен эшебездә бу бурычның хәл иткеч әһәмияте бар. Иптәш Молотов болай диде: „Политик, экономик, культура, оештыру һәм барлык башка төрле гаять зур мөмкинлекләребезне чын-чынлап аңлау һәм алардан халык интереслары өчен иң күп практик нәтиҗәләр алырлык итеп файдалану өчен безгә хәзерге чорда барыннан да бигрәк коммунистик тәрбия эшен барлык чаралар белән күтәрү кирәк“. Сүз, беренче чиратта, барлык гражданнарда хезмәткә һәм җәмагать милкенә социалистик караш тәрбияләү турында бара.

Илебездә коммунизм төзү өчен аңлы рәвештә һәм үз-үзләрен кызганмыйча көрәш алып баручы һәм эшчеләрнең, крестьяннарның күпчелек массасын үз артларыннан ияртеп баручы алдынгы кешеләр белән бер рәттән, бездә социалистик дәүләткә гаять зур зарар китерүче, артта калган, аңсыз, намуссыз кешеләр—летуннар, комсызлар, прогулчылар, ялкау кешеләр дә бар әле. Мондый кешеләр дәүләт исәбенә яшәргә, үзләре өчен дәүләттән күбрәк йолкырга яраталар. Шуннан калганы аларны кызыксындырмый.

Капиталистик караш калдыклары көнкүрештә дә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә дә бар (ялагайлык, гайбәт, балаларга игтибарлы карашның булмавы, хатын-кызга кимсетеп карау һ. б.). Безнең җәмагатчелегебез аларның һәрбер күренешенә бик тиз һәм рәхимсез отпор бирергә тиеш.

Хезмәт ияләренең аңында капиталистик караш калдыкларына каршы көрәш үзенең эченә хезмәт ияләренең аңындагы дини караш калдыкларына каршы көрәшне дә ала. Милли мәсьәләдә дә әле капиталистик караш калдыклары бетерелеп җитмәгән (великодержавие шовинизмы һәм җирле милләтчелек калдыклары).

Шәһәр белән авыл арасында яшәп килгән каршылыкны тәмам бетерү өчен дә күп эшлисе бар әле.

Безнең җитәкче кадрларыбыз марксизм-ленинизмны туктаусыз үзләштереп килсәләр, үзләренең теоретик дәрәҗәләрен күтәрсәләр, шул чагында хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү һәм коммунизм төзүдә эш тагын да уңышлырак барыр. Партиянең XVIII нче съездында иптәш Сталин кадрларны марксистик-ленинчел тәрбияләүнең гаять зур ролен аеруча күрсәтеп үтте. Иптәш Сталин, әгәр дә без кадрларыбызны идеологик яктан хәзерләргә булдыра алсак иде, әгәр дә без аларны тәмам өлгереп җиткән марксистлар-ленинчеләр итә алсак иде, „ул вакыт безнең барлык мәсьәләләребезнең уннан тугызы инде хәл ителгән дип санарга барлык нигезләребез булыр иде“ диде.

Иптәш Сталинның ВКП(б) ның XVIII нче съездында ясаган тарихи доклады һәм съездның карарлары—марксизм фәненә иң кыйммәтле хәзинә булды. Алар совет халкын һәм бөтен дөнья пролетарийларын коммунизмның тулы тантанасы өчен изге көрәшкә рухландыралар, җиңү юлын күрсәтәләр һәм яктырталар.

Иптәш Сталин докладында фәнни нигездә эшләнгән мәсьәләләр арасында социалистик дәүләт турындагы таглимат һәм совет интеллигенциясе турындагы таглимат төп урын алып торалар.

Көрәшебезнең һәм социалистик төзелешнең 20 еллык тәҗрибәсенә йомгак ясау нигезендә, җәмгыятебез үсешенең төп ике фазасына анализ ясау нигезендә иптәш Сталин капиталистик чолганыш шартларындагы социалистик дәүләт турында төгәлләнгән марксистик таглимат эшләде.

Иптәш Сталин, безнең шартларда социалистик дәүләтнең үлүе турындагы, аның куәтенең йомшавы турындагы һәр төрле сөйләнүләрнең безнең сыйнфи дошманнарыбызга гына файдалы икәнлеген исбат итте. Иптәш Сталин, капиталистик чолганыш яшәгәндә социалистик дәүләт ныгырга һәм үсәргә тиеш дип өйрәтә.

Маркс, Энгельс, Ленин таглиматын тагын да үстереп, илебезнең гаять зур тәҗрибәсен искә алып, иптәш Сталин, Ленинның бер илдә социализм төзү мөмкинлеге турындагы теориясен капиталистик чолганыш шартларында бер илдә коммунизм төзү мөмкинлегенә кадәр дәвам иттерде. Иптәш Сталин, әгәр дә капиталистик чолганыш бетерелмәсә, дәүләт коммунистик җәмгыять шартларында да яшәячәк дип күрсәтте. Ул гына да түгел, бары тик куәтле социалистик дәүләткенә һәм Кызыл Армиябезнең һәм Хәрби Диңгез Флотының совет чикләренең ышанычлы сакчысы булуы гына безнең алдагы уңышларыбызга, коммунизм төзүдә безнең эшебезгә чын гарантия була алалар.

Иптәш Сталин, социалистик дәүләт үзгәрешсез калмады, бәлки өзлексез үсеп һәм яхшырып килде дип күрсәтә. Илнең эчке һәм тышкы шартлары үзгәрү белән аның формалары һәм функ-

(Дәвамы 3 нче биттә).

ХУҖАЛЫК БУРЫЧЛАРЫН ПОЛИТИК ЭШКӘ НЫК БӘЙЛӘП АЛЫП БАРЫРГА

ҖИРЛЕ ПРОМЫШЛЕННОСТЬКА ИГТИБАРНЫ КӨЧӘЙТИК

Республикабызның җирле промышленносте соңгы елларда байтак кына үсте һәм алга китте. Мәсәлән, ТАССР ның җирле промышленность наркоматына караган предприятиеләр тарафыннан 1937 нче елны 27 миллион 263, 9 мең сумлык продукция эшләнеп чыгарылган булса, 1939 нчы елда бу сан 35 миллион 609,7 мең сумга җитте. Үсеш 30,6 процент тәшкил итә. Казандагы язу машиналары заводы, Чистайдагы мебель фабрикасы, Татметровес һәм инструменталь заводлары 1939 нчы елда үзләренең еллык планнарын арттырып үтәделәр.

Шулай да, бу беренче уңышлар гына безне һич тә тынычландыра алмыйлар әле. Чөнки без партиябезнең тарихи XVIII нче съезды карарларын тулысы белән үтәүгә ирешә алганыбыз юк. Бу өлкәдә безгә гаят зур эшләр башкарырга кирәк. Шуның өстәвенә быел без узган елга караганда начаррак эшли башладык. Галантерея фабрикасыннан башка предприятиеләр январь һәм февраль айлары планын үтәп җиткермәделәр.

Районнарда җирле промышленность предприятиеләрен булдыру, искеләрен үстерү һәм киңәйтү эше—иң артта калган тармакларның берсе. Ә бит без ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарлары нигезендә масса күләмендә кулланыла торган промышленность әйберләрен—галантерея, тегү промышленносте әйберләрен, мебель, кирпеч, известь һәм башка шундый киң куллану әйберләрен тулысы белән үзебездә булдырырга ирешергә тиешбез. Моның өчен республикабызның эчке мөмкинлекләре гаят зур. Тик моның өчен бу бай эчке мөмкинлекләрдән файдалану тугел. Монда без дә, Наркомат, завод һәм фабрика җитәкчеләре, шулай ук район оешмалары да гаепле. Без күбрәк өлкә күләмендә әһәмияте булган зуррак предприятиеләр белән мавыгып, район промышленносте игътибарны йомшарттык. Нәтиҗәдә район промышленносте бик акырын үсә.

Бу өлкәдә район оешмалары безгә, Наркомат работникларына һәр яклап булышлык курсәту урына, киресенчә, җавапсыз карау курсәтәләр. Моны дистәләрчә фактлар белән расларга мөмкин. Мәсәлән, Бөгелмә һәм Балык Бистәсе районнарында мыналардан сырылган мебель фабрикалары бинасын алып, икенче оешмаларга биргәннәр. Чаллы районында үлчәү приборлары мастерское биналарын залына әверелгәннәр. 1939 нчы елда без районнарда 14 яңа предприятиеләр ачу планы артыгы белән үтәдек. Мең бәләләр белән 4 кенә предприятие эксплоатациягә бирелде.

Моның сәбәбе нәрсәдә соң? Кайбер район җитәкчеләре: „төзү материаллары җитешми“ дип акланырга омтылалар. Бу көлке, әлбәттә. Чөнки республикабыз төзү материалларына гаят бай республикаларның берсе. Тик менә урыннардагы оешмаларның теләге һәм инициативасы гына җитешми.

Бу елның башларында гына эшләнеп беткән кайбер яңа мастерскойлар белән дә шундый ук хәл. Арчада чүлмәк җитештерү мастерское, Тәтеш, Саба һәм Кызыл Йолдыз районнарында мебельләр эшләү мастерскойлары „акча юк“ сылтавы белән хәзергәчә эшкә җибәрелмәгәннәр. Массаның киң куллану товарларына булган соравын тәэмин итүгә чакырылган бу мастерскойларның хәрәкәтсез яткырылуларын, район оешмаларының 10—12 мең сум акча таба алмауларын, хиянәт дияргә кирәк.

1940 нчы ел бу өлкәдә арттә калучылыкны бетерү елы булырга тиеш. Без, республика күләмендә әһәмиятле предприятиеләр буенча продукция эшләп чыгаруны 10 процентка, ә район промышленносте буенча 38 процентка күтәрүне билгеләдек. Шул ук вакытта товарларның ассортиментларын төрләндерү һәм җирле промышленность калдыкларыннан файдалану эшенә дә зур игътибар бирелә. Быел республикада район промышленносте буенча 21 урында яңа предприятиеләр төзелеп, эксплоатациягә бирелергә һәм алар тарафыннан 876 мең сумлык товар җитештерелергә тиеш.

Госплан турында бер-ике сүз. Эшне планлаштыруда әһәмиятле урын тоткан бу учреждение үз бурычын тулы үти дип, әйтеп булмый әле. Татарстан предприятиеләрендә җирле калдыклар шактый күп. Бу калдыклардан тулы файдаланганда киң куллану товарлары эшләп чыгаруны хәзергегә караганда күп кенә арттырырга мөмкин. Ләкин Госплан бу мөмкинлектән файдалануны планлаштырмый. Киресенчә, Мехкомбинат фабрикаларының калдыклары башка өлкәләргә җибәрелә һәм шул ук калдыклардан эшләнгән товарлар яңадан Казанга кайтарылу фактларын күп кенә курсәтергә мөмкин. Бу исә транспортка артык йөк булып төшә һәм әйберләр үзенә төшү бәясе кыйммәтләнә.

Калдыклардан дөрес файдалану яхшы планлаштырылса һәм алардан киң куллану товарлары җитештерүне киң җәелдерергә предприятиеләр челтәрен киңәйтергә кирәк. Җирле промышленность үстерү өчен безнең республикабызда мөмкинлекләр зур.

Филимонов.

ТАССР ның Җирле Промышленность Халык Комиссары.



ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе делегатлары. Сулдан унга—А. Г. Гыйззәтуллина (Калинин районы), Ф. М. Галанин (Минзәлә районы), Х. В. Вәлиуллин (Калинин районы), К. А. Ибатуллин һәм С. Т. Корабальников (Красный Бор районы) иптәшләр.

М. Солтанов фотосы.

Югары уңыш өчен без ничек көрәшәбез

Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин партиянең тарихи XVIII нче съездында социалистик авыл хуҗалыгы алдына гектарыннан кимендә 12—13 центнер уңыш алу бурычын куйды. Калинин районының авыл хуҗалыгы алдынгылары юлбашчыбыз тарафыннан куелган бу бөек бурычны үтәү өчен большевикларча көрәшәләр. Шушы нигездә узган елны ук инде күп кенә колхозларда югары уңыш яулап алынды.

Районыбызның алдынгы кешеләре 1940 нчы елда тагын да мулрак уңыш яулап алу—һәр гектардан 100 пот уңыш алу өчен көрәшкә чакыру белән республикабызның барлык колхозчыларына, колхозчы хатын-кызларына, МТС һәм совхоз эшчеләренә, авыл хуҗалыгы белгечләренә мөраҗәгать иттеләр.

Бу гүзәл хәрәкәт башлануга өч ай вакыт үтте. Шушы вакыт эчендә югары уңыш алуны тәэмин итүгә юнәлдерелгән күп кенә практик чаралар үткәрелде. Райондагы 65 колхоздан 38 колхозда 73 ефремовчы звено төзелде. Бу звеноларга колхоз производствосында иң яхшы эшләүчеләрдән 474 кеше тартылды. 8 колхозда стахановчылар мәктәбе һәм барлык колхозларда агротехника түгәрәкләре оештырылды һәм алар хәзер яхшы гына эшләп киләләр. Шулай ук 130 яровизатор, 47 агротехник, 118 тракторчы хәзерләнде.

Язгы чәчүгә материал хәзерлекнең торышы буенча да, узган елгы белән чагыштырганда, уңышлар шактый зур. Мәсәлән, 1939 нчы елны 10 нчы мартка тракторларга ремонт ясау планы бары 55 процент кына үтәлгән булса, быел бу эш 10 нчы мартка 90 процент үтәлде. Узган елны шул ук вакытка тракторларга ягулык материаллары ташу планы 89 процентка үтәлгән булса, ул быел 100 процент үтәлде. 1939 нчы елны 10 нчы мартка язгы чәчүгә тулы хәзерлек бары тик 15 колхозда тәэмин ителгән булса, быел чәчүгә хәзерлек эше 36 колхозда төгәлләнде.

Без бу беренче уңышларга, барыннан да элек, райондагы партия һәм комсомол оешмаларын язгы чәчүгә хәзерлек өчен көрәшкә туплау нәтиҗәсендә ирештек. Күп кенә коммунистлар һәм комсомолецлар югары уңыш өчен көрәштә авангардлык үрнәге күрсәтәләр. Мисаль өчен Ленин исемендәге колхозны алыйк (председателе партия кандидаты—Әхмитов). Бу колхоз районның иң зур колхозларыннан берсе булып тора һәм анда язгы чәчүгә хәзерлек эшләре тулысынча төгәлләнде. Шулай ук коммунистлар җитәкчелек итә торган „Удар“, „Кызыл тан“, „Кызыл чишмә“, „Имәнле“ һәм Тельман исемендәге колхозларда да язгы чәчүгә хәзерлек тулы тәэмин ителгән.

Молотов исемендәге колхозның беренче бригадасы (бригадиры ВКП(б) кандидаты иптәш Шаваев) районда иң алдынгы бригадалардан хисаплана. Бу бригада 20 нче февральдә үк инде язгы чәчүгә хәзерлек эшен яхшы итеп төгәлләде һәм агротехника чараларын арттырып үтәде. „Бүләкбул“ колхозының 3 нче бригадасы (бригадиры партия кандидаты иптәш Абдуллин) тирес чыгару планын 122 процент, көл җыю планын 151, фекаль җыю планын 190 процент итеп үтәде һәм язгы чәчүгә бөтен яктан тулы хәзерлекне тәэмин итте. Берничә елдан бирле артта калып килгән „Правда“, „Октябрьнең 12 еллыгы“ һәм Чапаев исемендәге колхозларда да чәчүгә хәзерлек эшләре яхшы гына бара. Бу колхозларга ВКП(б) членнары Гайнанов, Хәбибуллин һәм ВКП(б) кандидаты Садыйков иптәшләр җитәкчелек итәләр. Менә мондый мисальләрне күп кенә китерергә мөмкин.

Ләкин язгы чәчүгә хәзерлек эшендә шундый уңышлар булу белән бергә, кимчелекләр дә бар әле. Мәсәлән, тракторларга ремонт ясау планының әлегә кадәр тулысынча үтәлмәве язгы чәчүгә хәзерлек эшендә иң зур җитешсезлекләрнең берсе булып тора. Кайбер башлангыч парторганизацияләр язгы чәчүгә хәзерлек эше белән җидди рәвештә шөгыльләнмиләр. Чуракай, Кужәкә, Олы Имән авылларындагы башлангыч партоешмалар бу мәсьәләдә аеруча начар эшлиләр.

Калинин районы 1940 нчы елда Татарстанда иң югары уңыш алуны үзенә бурыч итеп куйды. ВКП(б) райкомының, район башкарма комитетының һәм партия, совет оешмаларының сугышчан бурычларыннан берсе, ул: алдынгы колхозчыларның бай тәҗрибәләрен барлык колхозчылар массасына күчерүдән гыйбарәт.

Вәлиуллин.

ВКП(б) райкомы секретаре.

Колхоз активы белән эшләү нәтиҗәсе

Балтач районы, Барбаш авылында башлангыч партоешма 1939 нчы елның маенда оештырылган иде. Бу оешма үзенең эшкә башлаган көненнән үк, партиябезнең тарихи XVIII нче съезды карарларын колхозчылар массасына аңлату эшләрен киң җәеп җибәрде. Партоешма үз тирәсенә колхозчылардан һәм авыл интеллигенциясеннән зур актив туплады һәм алар арасында партия-масса эшләрен системалы рәвештә алып бара башлады.

Партоешма Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән бирелгән кешеләр хисабына үсә. Соңгы вакытта авылның иң алдынгы кешеләреннән 6 иптәш партия сафларына кабул ителде. ВКП(б) га яңа алынган иптәшләр арасында эшләүгә зур игтибар бирелә. Алар белән партиянең устав һәм программасын өйрәнү эше оештырылды. Партия һәм хөкүмәт карарларын өйрәнү системалы рәвештә алып барыла.

Партоешма янында 27 кешедән торган агитколлектив эшләп килә. Партоешма агитаторлар белән семинарлар үткәрү эшен тәртипле рәвештә алып бара, аларның киңәшмәләрен үткәрә. Агитаторлар партия һәм хөкүмәт карарларын хезмәт ияләренә аңлату буенча зур эшләр башкаралар. Бу эштә Гарифуллин, Әхмитова, Булатова, Хәсәнев иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр.

Тәрбия эшләрен яхшы итеп кую нәтиҗәсендә хезмәт ияләренең политик һәм производство активлыклары көннән-көн үсә. Барбаш партоешмасы җитәкчелек итә торган „Кызыл Татарстан“ һәм „Кызыл дулкын“ колхозлары язгы чәчүгә хәзерлек буенча районда иң алдынгы колхозлардан саналалар. Һәр ике колхозда да ремонт эшләре февраль аенда ук 100 процентка төгәлләнде. Агрономия чараларын тормышка ашыру эше „Кызыл дулкын“ колхозы буенча 130, „Кызыл Татарстан“ колхозы буенча 111 процент итеп үтәлде. Без бу уңышларга барыннан да элек, колхоз активы белән көндәлек эш алып бару, хуҗалык бурычларын политик эш белән бергә бәйләп алып бару нигезендә ирештек.

Партоешма колхоз активы белән эшләү, авылда политик-масса эшләрен җәелдерү, колхоз производствосына җитәкчелек итү буенча ирешелгән уңышларын тагын да ныгытыр. һәм барлык колхозчыларның да колхоз производствосында яхшы эшләүләренә ирешеп, язгы чәчүне большевикларча үткәрүне тәэмин итәр.

Г. Сабиров.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды

(Ахры. Башы 2 нче биттә).

цияләре дә үзгәреп килде. Хәзерге чорда, безнең илебездә эксплоататор сыйныфлар тәмам бетерелгән һәм социализм төзелгән чорда, ил эчендә дәүләтнең төп бурычы хуҗалык-оештыру һәм культура-тәрбия өлкәсендә тыныч хезмәттән гыйбарәт.

Иптәш Сталин партиянең һәм дәүләтнең алтын фонды булган кадрлар турындагы, аларны дөрес сайлап алу, яңа кешеләр үстерү һәм күтәрү турындагы, кадрларны дөрес урнаштыру турындагы, аларны эш барышында тикшерү турындагы, карт һәм яш кадрларны „партиянең һәм дәүләтнең җитәкче эшендә гомуми бер оркестрда“ бергә кушу турындагы таглиматны тудырды.

Съездның ВКП(б) уставында үзгәрешләр турындагы карарының партиябез тормышында зур әһәмияте бар. Алар большевизмның Ленинчел — Сталинчыл ныклы принципларын саклап калып, партиянең оештыру коралын тагын да үткенәйтәләр, аның көчен һәм куәтен тагын да ныгыталар, коммунизм төзелешенең тарихи бурычларын уңышлы хәл итү өчен аны тагын да сугышчанрак итәләр. ВКП(б) ның яңа уставына „Партия һәм комсомол“ дигән махсус бүлек кертелде. Бу бүлек партиянең комсомолга гаят зур ышанычы белән сугарылган һәм ул хуҗалык һәм дәүләт төзелешендә катнашу өчен яшьләр алдында чикләнмәгән мөмкинлекләр ача.

Съезд гаят дәрәҗәдә бердәмлек һәм оешканлык шартларында үтте. Съездның бөтен эшен сугарган омтылыш бердәмлеге, хәрәкәт бердәмлеге, фикерләр һәм хисләр бердәмлеге партиябезнең көчен һәм җинелмәслеген, аның сафларының тимердәй нык тупланганлыгын, партиянең Ленинчел—Сталинчыл төп юлының тантанасын, тулысынча җинүен күрсәтте.

XVIII нче съездан бирле бер ел вакыт үтте. Ватаныбыз яңа гүзәл җиңүләргә иреште. Съездның карарлары уңышлы рәвештә тормышка ашырыла.

Социалистик промышленностебыз туктаусыз үсә. Аның үсеш темплары квартал саен арта килде, үткән елгы күрсәткечләрдән шактый югары булды. Уртача алганда промышленность продукциясе 14,7 процентка үсте, ә 1938 нче елны аның үсеше 12 процент булды. Бу да шулай ук өченче бишьеллык план заданиесеннән артып китә. Бу план буенча уртача еллык үсеш 14 процент итеп билгеләнгән иде. 1939 нчы елның 9 ае эчендә генә дә совет индустриясе сугышка кадәрге 10 ел эчендә бөтен патша Россиясе промышленносте биргәннән күбрәк продукция бирде. Безнең оборона промышленностеның көчле үсеше бигрәк тә ачык күренә. 1939 нчы елны бу үсеш 46,5 процент булды.

1939 нчы елның 10 ае эчендә алынган саннарга караганда, промышленностьта хезмәт җитештерүчәнлеге 17 процентка үсте, димәк план арттырып үтәлде. Ә авыр машина төзелеше предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеге 22 процент күтәрелде. Стахановчылык хәрәкәтенең яңа формалары—күп станокларда эшләү, берьюлы берничә профессияне алып бару формалары килеп чыкты. Боларның киләчәге гаят зур. Москвадагы инструмент заводы инициативасы буенча илебездә хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү буенча бишьеллык планны дүрт елда үтәү өчен киң хәрәкәт башланды.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе колхоз һәм совхоз кырлары стахановчыларының гаят зур уңышларын, социалистик игенчелекнең туктаусыз күтәрелүен ачык итеп күрсәтте. Ун меңнәрчә колхозлар узара ярыш алып баралар, 1940 нчы елгы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу хокукы алу өчен көрәшәләр.

Үзбәкстан колхозчылары гүзәл халык хәрәкәтен башлап җибәрделәр. Искиткеч кыска срок эчендә колхозчылар көче белән Зур Фиргань каналы төзелде һәм бу канал хөкүмәт комиссиясе тарафыннан отлично дип табылды.

Бу инициатива, стахановчылык хәрәкәтенең бер формасы буларак, бик тиз һәм киң күләмдә җәелде. Таҗикстан колхозчылары бу каналны үз республикалары территориясендә 79 километрга озайттылар. Күп кенә урыннарда культуралы юллар төзү хәрәкәте туды.

Күптән түгел генә хезмәт ияләре депутатлары Советларына булган сайлаулар хезмәт ияләре массасының политик активлыгы бик нык үскәнлекне күрсәттеләр. Бу сайлаулар коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогының көчен, партиябезнең гаят зур авторитетын тагын да ачыграк күрсәттеләр һәм дәүләтебезнең куәтен тагын да көчәйттеләр. Сайланган депутатлар барсы да—шушы җиңелмәс блокның кандидатлары.

Культураны үстерү, хезмәт ияләренең тормыш дәрәҗәсен тагын да күтәрү программасы уңышлы рәвештә үтәлә.

Большевиклар партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең дөрес политикасы халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә дә илебезнең гүзәл уңышларга ирешүен тәэмин итте. Иптәш Сталинның алдан әйткән даһи сүзләре тулысынча расланды.

Үзенең докладында халыкара хәлгә анализ ясап, иптәш Сталин, Англиядәге һәм Франциядәге сугыш уты кабызучыларның казынуларын даһиларча фаш итте һәм алар тарафыннан башланган зур һәм куркынычлы политик уенның алар өчен җидди җимерелү белән тәмам булуы мөмкинлеген аеруча күрсәтте. Аннан соңгы вакыйгалар моны тулысынча расладылар. Иптәш Сталин, Совет дәүләтенең тышкы политикасы ачык һәм аңлаешлы диде. Тынычлык эшен һәр вакыт яклап, халыклар арасында чын тынычлык өчен көрәшеп, без „совет чикләренең кагылгысызлыгын бозарга маташучы сугыш уты кабызучыларның ударына икеләтә удар белән“ җавап бирергә һәрбер минутта хәзер торабыз.

Империалистларның СССР ны Германия белән сугыштырырга маташулары барып чыкмады. Ике бөек ил халыклары арасындагы дошманлыкка Советлар Союзы белән Германия арасында һөҗүм итешмәү турындагы пакт белән һәм дуслык турындагы договор белән чик куелды.

Англиянең һәм Франциянең Көнчыгыш Европаны канлы сугыш кырына әйләндерү планнары өзелде. Данлыклы Кызыл Армия, үзенең бөек тарихи бурычын үтәп, кардәшләребез украинлыларны һәм белорусларны паннар изүеннән азат итте. 1939 нчы елның 17 нче сентябрен, Белоруссиянең һәм Украинаның көнбатыш өлкәләрен азат итү көнен хезмәт ияләре мәңге исләрендә тотарлар.

СССР халыкларының тату семьясенә 13 миллион яңа совет гражданнары кушылды. В. М. Молотовның бик үткен итеп әйтүенчә, 1939 нчы елны капиталистик дөньяга бераз кысрыкланырга һәм чигенергә туры килде, ә Советлар Союзы үзенең чикләрен көнбатышка таба шактый киңәйтте.

СССР белән Балтыйк буе илләре—Эстония, Латвия, Литва, Финляндия демократик республикасы арасында үзара ярдәмләшү турында төзелгән договорларның гаят зур әһәмияте бар. Бу договорлар безнең чикләребезгә куркынычсызлыкны тәэмин итәләр һәм Советлар Союзының хәрби куәтен тагын да ныгыталар. Шуның белән бергә, алар безнең Балтыйк буендагы күршеләребезнең бәйсез яшәвен тәэмин итәләр һәм империалистик дәүләтләрнең сугыш һөҗүме куркынычын бетерәләр. Совет хөкүмәте Литва дәүләтенә аның борынгы башкаласын—Вильноны биреп, капиталистик дөнья шартларында азчылык халыкларга карата һичбер булмаслык ихтирам үрнәге күрсәтте.

Хәзерге вакытта безнең батыр Кызыл Армиябез ак финнәргә каршы көрәштә Ленинград шәһәренең һәм бөтен илебезнең обороносын тәэмин итә, иң куркынычлы сугыш учакларыннан берсен бетерә һәм Англия—Франция лакейлары булган Маннергейм—Таннер шайкасыннан азат булуда хезмәтчел фин халкына ярдәм итә.

XVIII нче съездан соң үткән бер ел партия һәм дәүләт кадрларын марксистик-ленинчел тәрбияләүне күтәрү эшендә дә бик уңышлы ел булды. Бу эштә ВКП(б) тарихының кыскача курсы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының пропаганда турындагы карары басылып чыгу гаят дәрәҗәдә зур әһәмият алды. Марксизм-ленинизмны өйрәнүнең иң әһәмиятле методы булган үзлегеннән эшләү киң күләмдә җәелде. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ партияле һәм партиясез большевикларның өстәл китабына әверелде.

Матбугат пропагандасы ягыннан зур тамрынган үзгәрде. Өлкә, край һәм республика матбугатында пропагандистлар мәкаләләренең әһәмияте күтәрелде, ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә ярдәмгә лекцияләр һәм консультацияләр басыла. Газеталар һәм журналлар тирәсенә иң яхшы пропагандистлар һәм партия литераторлары кадрлары берләшәләр.

Пропаганда буенча лекцияләр системасы киң күләмдә җәелде. Партиянең барлык өлкә, край комитетларында, милли республикалардагы компартияләрнең Үзәк Комитетларында лекторлар группалары төзелде.

Партиянең җитәкче органнарына хәзер бара торган сайлаулар партиянең барлык членнарының, барлык оешмаларының Ленинче-Сталинчы Үзәк Комитет тирәсенә нык тупланганлыкларын, Ленин—Сталин эшенә һәм партиянең бөек юлбашчысы иптәш Сталинга чиксез бирелгәнлекләрен күрсәтәләр.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды социалистик Ватаныбыз тарихында яңа сәхифәне ачты. Ул совет халкын коммунизм өчен, Сталинчыл өченче бишьеллыкны уңышлы үтәү өчен көрәштә куәтле корал белән коралландырды. Съездан соң үткән бер ел эчендә булган гүзәл уңышлар совет халкын съезд тарафыннан куелган тарихи бурычларны тизрәк үтәүгә, коммунистик җәмгыять төзелешен тизрәк төгәлләүгә рухландыралар.

Н. Матюшкин.

(Мәкалә кыскартып алынды).

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 8 март. Кичә кич белән Парижда игълан ителгән рәсми белдерүдә: „Вогезы тавының көнчыгыш өлешендә Франция һәм Германия патрульләренең шактый активлыгы" сизелде дип күрсәтелә.

Бүген иртәнге белдерүдә болай диелә: „Нид елгасынан көньяк-көнчыгышта дошманның һөҗүме уңышсыз чыкты".

ЛОНДОН, 8 март. Моннан элек хәбәр ителгәнчә, 5 нче мартта Германия разведчиклары отряды Мажино линиясендә, Англия гаскәрләренең алгы постларыннан берсенә һөҗүм иткән. Англия хәрби советының хәбәр итүенә караганда, ике кеше үтерелгән һәм 14 кеше хәбәрсез югалган. Алар пленгә төшкәннәрдер, дип уйлыйлар.

Авиация министрлыгенең хәбәр итүенә караганда, кичә көндез Англия истребителе Шотландиянең төньяк-көнчыгыш ярлары янында Германия самолетын бәреп төшергән.

БЕРЛИН, 8 март. Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәгеләрне хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта әһәмиятле вакыйгалар булмады. Германия самолетларының уңышлы хәрәкәт итүләре нәтиҗәсендә, зенит артиллериясенең көчле ут ачуларга да карамастан, Англиянең сугыш корабларгы күзәтчелегендә бара торган унбер сәүдә пароходы батырылган һәм зарарландырылган. Германиянең шушы операциядә катнашкан барлык самолетлары да бер нинди югалтусыз үз базаларына кайттылар. Германиянең төньяк Шотландия өстендә күзәтү очышлары ясаган бер самолеты үз базасына кайтмады. 7 нче мартка каршы төндә Англиянең аерым самолетлары Германия бухтасы өстендә очып йөрделәр. Англиянең барлык самолетлары да Германия ярларына кадәр килеп җитмичә, кире борылдылар. Дошманның Төньяк һәм Көнбатыш Германия өстендә очып йөргән самолетлары 8 нче мартка каршы төндә Даниянең һәм Люксенбургның нейтральлеген бозганнар".

ЛОНДОН, 7 март. Рейтер мәгълүматларына караганда, Англиянең Даунстагы дингез контроль пунктында Италиянең Германия күмерен төягән 13 пароходы тоткарланды. Алардан 5 се кичә кич белән тотылган. Күмер Англия портларында бушатылыр дип уйлыйлар.

ЛОНДОН, 8 март. Кичә Англия ярлары якынында Италиянең 5.355 тонна авырлыгындагы „Амелия Лауро" дигән пароходы баткан. Бу пароходта булган 29 кеше (шулардан 3 се яраланган) коткару көймәсенә алынганнар.

НЬЮ-ЙОРК, 7 март. „Нью-Йорк таймс"ның хәбәр итүенә караганда, Канада хөкүмәте Ирландиядән, Португалиядән һәм Төркиядән башка Европаның барлык нейтраль илләренә чыгарыла торган товарларга үзенең лицензия кертәчәнлеген белдергән. Хөкүмәт контрабанда товарлары исемлегенә сугыш кирәк-яраклары, химия продуктлары, ягулыклары, транспорт средстволары, металлы, азык әйберләрен, кием-салымны һәм башкаларны керткән. (ТАСС).

ГЕРМАНИЯ ИЛЧЕЛЕГЕНЕҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

Ассошиэйтед Пресс агентлыгы Гитлер белән АКШ президенты Рузвельтның уполномоченные Уэллес арасында 3 нче мартта Берлинда булган сөйләшүләрнең эчтәлеге турында үзенең Берлиндагы хәбәрчесенең белдерүен хәбәр итте. Германиянең Москвадагы илчелеге бу уңай белән түбәндәгеләрне белдерде:

„Берлинда Американың махсус делегаты Уэллес белән сөйләшүләр турында чит ил матбугатында хәбәрләр чыгу уңае белән Германиянең ышанычлы органнары, бу сөйләшүләрнең эчтәлеген игълан итмәскә дигән карарны ике якның да нык һәм дәүләт төстә үтәүләрен күрсәтеп үтәләр. Шулай итеп чит ил матбугаты хәбәрләренең эчтәлеге—һәр төрле нигездән мәхрүм ителгән һәм Германия белән Төньяк Америка Кушма Штатлары арасында ачыктан-ачык ышанмаучылык таратырга бөтен дөнья җәмәгатьчелегенең фикерен буталышка кертергә маташу булып тора".

Риббентропның Римгә баруы

БЕРЛИН, 8 март.(ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германиянең чит ил эшләре министры Риббентроп 9 нчы мартта Римгә китә.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньнин секторында, японнарның Саньтаннан (Наньниннан 15 километр төньяк-көнбатышта) кысрылып чыгарган кытай гаскәрләре Наньниннән 10 километр ераклыкта сугыш алып баралар.

Хәбәр итүләргә караганда, хәзер Наньнин фронтында японнарның тулы булмаган ике дивизиясе бар. Алардан берсе Наньнин—Циньчжоу линиясендә, икенчесе Наньнин районында хәрәкәт итә.

Японияның Наньнин фронтындагы гаскәрләре арасында соңгы көннәрдә сугышка каршы кул белән язылган листовкалар табылган. Бу листовкаларда: „Япониянең Төньяк Кытайдагы экспедицион армиясенең сугышка каршы лигасы" имзасы белән таратылалар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә кытай гаскәрләре Уюаннан Баотоуга таба баручы японнарның автоколоннасына засада ясаганнар. Сугыш нәтиҗәсендә японнар сугыш әйберләре төягән 20 гә якын автомобильләрен югалтканнар. Кытай гаскәрләре японнарны Уюаньда камап алуны дәвам иттерәләр.

Сайтоны Япония парламентыннан чыгару

ТОКИО, 8 март. (ТАСС). Барлык газеталарның игътибары әйбуенча Япония парламентына үтә катлаулы вакыйгага—Сайтоны эшенә юнәлдерелгән. Япония парламентының түбәнге палата председателе Кояма, дисциплина комитеты карарларына һәм түбәнге палатаның яшерен утырышы карарларына таянып, палатаның ачык пленар утырышында парламент членнары Сайтоны „парламент законының 96 нчы статьясен бозган өчен парламенттан чыгарылырга" дип белдергән. Шуны әйтергә кирәк, Сайтоны кемнәр яклаганын белү өчен Сайтоның тулы хәрәкәтен өйрәнергә кирәк. Шуның хатыйбы Сайтоның тарафдарлары, күп кенә депутатлар „авыру булуларын" сылтау итеп, бу утырышта катнашудан баш тартканнар.

Сайто „эше" тирәсендә җәелгән кискен политик көрәштә Сайтоны парламенттан чыгару турындагы булган кешеләр җиңгәннәр. Минсейто партиясе һәм сейюкай партиясенең Кухара фракциясе утырышта ясалган басым нәтиҗәсендә буйсынырга мәҗбүр булганнар. Бер үк вакытта минсейто партиясенең күп кенә җитәкчеләре һәм күренекле членнары, Сайто эше өчен җаваплылыкны үз өсләренә алып, партиянең җаваплы постларыннан отставкага чыгачакларын белдергәннәр. Огава, Уцигаски һәм Тавара отставкага чыгачакларын белдергәннәр. Ләкин минсейто партиясенең председателе Мацида аларның ябдан уйлап карауларын һәм үз постларында калуларын сораган.

Сайто эше партияләр арасындагы көрәшне тагын да күбрәк көчәйтер. Һич шиксез, Сайтоны парламенттан чыгару эшендә хәл иткеч сүз хәрби кешеләр өлешенә туры килә, алар, Сайто үзенең чыгышы белән, Кытайда алып барыла торган сугышның максатларын мыскыл итте, дип хисаплыйлар.

Болгария самолетының Төркия чиген бозуы

СОФИЯ, 9 март. (ТАСС). 8 нче мартта Болгария агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 6 нчы мартта кичке белән хезмәт буенча очкан Болгария самолеты кичә янгыр һәм томан сәбәпле адашты һәм Төркия территориясенә, шәһәре янында, эчкә керәк булган урынга төшәргә мәҗбүр булган.

СССР ның Памирдагы чиге. РӘСЕМДӘ: пограничниклар.
В. Шаховский фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ӘДӘБИЯТ ТҮГӘРӘКЛӘРЕ

Серго Орджоникидзе исемендәге завод янында рус һәм татар телендә әдәбият түгәрәкләре оештырылып, эшкә керештеләр. Һәр ике түгәрәккә башлап язучы һәм әдәбият белән кызыксынучы стахановчы эшче яшьләр, инженер-техник работниклар бик нык кызыксынып йөриләр.

5 нче мартта, түгәрәкләрнең берләштерелгән җыелышы үткәрелде.

Башлап язучыларның тәкъдиме буенча, җыелыш республикабызның XX еллыгына багышлап татар һәм рус телләрендә ике альманах чыгару турында карар кабул итте. *Г. Миңнул.*

ЯҢА МӘКТӘПЛӘР

Узган ел Татарстанда башлангыч һәм тулы булмаган 15 яңа мәктәп салынды. Аларны төзү расходларына 4 миллион 500 мең сум расход тотылды. Казанның Калуга бистәсендә, Аракчинода һәм Бөгелмәдә яңа мәктәпләр төзелде.

Быел Октябрь, Чистай, Кызыл Йолдыз, Тархан, Кайбыч районнарында һәм башкаларда 19 яңа мәктәп салына башлый. Шәһәрнең Ленин районында 880 урынлы мәктәп төзелеп бетә. Чаллыда һәм Кукмарада 400 әр урынлы мәктәпләр салына. Бу төзелешләр өчен 4 миллион сумнан артык акча билгеләнде.

Совет төзелеше курслары

Хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр һәм авыл советлары башкарма комитетлары работникларының белемен күтәрү өчен Казанда һәм Чистайда курслар ачыла. Курслар ике сменада 300 кешене үткәрәчәкләр. Укулар шушы көннәрдә башлана. Казандагы курсларда уку срогы 6 ай, Чистай курсларында—4 ай. Беренче сменада уку өчен Казандагы курсларга 120 кеше, Чистайдагы курсларга 50 кеше кабул ителде. Курсларны оештыру өчен 446 мең сум акча билгеләнде.

Зарафшан каналы төзелешендә

Тажикстан ССР белән Үзбәкстан ССР арасында 140 километр озынлыкта Зарафшан каналы төзелгән иде. Хәзерге көндә Үзбәкстанның Кәттә Курган шәһәре янында шул канал системасында зур мәйданда су саклау урны ясала. Колхозчылар бу эштә актив рәвештә катнашалар.

Зарафшан каналын төзү һәм су саклау урыннары ясау аркасында Үзбәкстанда һәм Тажикстанда мамык игелә торган мәйдан тагын да киңәя.

И. Мугарипов.

СТУДЕНТЛАР ӨЧЕН ТУЛАЙ ТОРАК

Соңгы елларда Казандагы институтлар өчен берничә зур бина салынган иде. Хәзер Ершов кырында Казан Дәүләт университеты студентлары өчен зур тулай торак төзү эшләре алып барыла. 500 кешене урнаштырырлык бу йортта студентлар өчен уңайлы бүлмәләр һәм заллар булачак. Йортны төзүгә узган ел 1 миллион 359 мең сум акча тотылган иде. Быел аны тәмам итүгә 200 мең сум җибәрелде.

МЕДИЦИНА ҖИҺАЗЛАРЫ

Аптекалар баш идарәсенең Татарстан бүлеге быел СССР ның төрле заводларында эшләп чыгарыла торган бик күп медицина җиһазлары кайтара. Неврохирургия өчен инструментлар, операция бүлмәләре өчен шәүләсез лампалар, күчмә ренгент аппаратлары, аш казанын тикшерү өчен гастроскоплар, бик күп төрле лаборатория җиһазлары—барлыгы 2 миллион 200 мең сумлык медицина җиһазы кайтарылачак.

Соңгы елларда Татарстанның дәвалау учреждениеләренә 60 микроскоп, теш кабинетлары өчен 25 кресло, 7 рентгеноустановка, физиотерапия өчен 100 дән артык аппарат, йөрәкнең эшләвен тикшерү өчен 2 электрокардиограф, бала тудыруны авыртусызландыру өчен 2 данә „Вега" аппараты һәм башка күп кенә өр яңа приборлар алынды. (ТатТАСС).

ЯЗЫН БАЛЫК ТОТУ АЛДЫННАН

Татарстанның балыкчылык колхозлары язын балык тотуга хәзерләнәләр. Бу эшкә 94 бригада, 1.000 гә якын балыкчы катнашачак. Балык тоту судноларына ремонт ясау тәмамланып килә. Язын балык тотуда моторлы 14 баркас йөреп торачак. Шуларның 3 се 30 ар ат көчле яңа баркаслар.

Хәзер Волга һәм Кама затоннарында боз астыннан балык тоту бара. Тәтеш районы балыкчылары февральнең өченче декадасында 123 центнер, Кама Тамагында 42 центнер, Зөядә 40 центнер балык тоттылар. (ТатТАСС).

ТУРИЗМ ҺӘМ ЭКСКУРСИЯЛӘР

Татарстанның туризм һәм экскурсияләр идарәсе быелгы сезонда зур эш программасы билгеләде. Туристлар һәм экскурсантлар саны берничә тапкыр артачак. Зөя елгасының Волгага кушылган урнындагы туристлар лагерында узган ел 1.460 кеше булган иде. Быел анда 1926 кеше булачак. Казан белән Ульяновский арасында байдаркаларда ясала торган 12 көнлек традицион походта үткән ел 100 кеше катнашкан булса, быел бу походта 300 кеше катнашачак. Казан шәһәре белән таныштыру өчен үткәрелә торган экскурсияләрдә быел 200 мең экскурсант катнашачак.

ТРАКТОРЧЫЛАР ЯҢА ЙОРТЛАР САЛАЛАР

Базарлы Матак МТС ының 12 нче номерлы трактор бригадасы тракторчылары эштә стахановчылык үрнәкләре күрсәтәләр. Бригада язгы чәчүгә хәзерлекне районда беренче булып тәмамлады, тракторларга ремонт ясауны яхшы сыйфатлы итеп срогыннан алда төгәлләде.

Бу бригада үткән елгы кыр эшләрендә дә яхшы эшләде. Һәр трактор белән 911 гектар җир сөреп, 2.571 килограмм ягулыкка экономия ясалды. Стахановча эшләү нәтиҗәсендә тракторчыларның көнкүреш шартлары нык яхшырды. Алар хезмәт көннәренә күп кенә ашлык һәм акчалата доход алдылар.

Һәрбер тракторчының сыеры, вак терлекләре бар. Бригадир Галиуллин, тракторчы Галиев, Яруллин һәм Хәнәфиев иптәшләр 2—3 мең сумга төшереп яңа йортлар салдылар. (ТатТАСС).

Париж Коммунасы көненә хәзерлек

Казан Тимер Юлы Идарәсенең МОПР оешмасы Париж Коммунасы көненә хәзерләнә. МОПР комитеты, политбүлек белән берлектә, Париж Коммунасы еллыгы турында беседалар үткәрү өчен агитаторлар билгеләде. Агитаторлар хәзер барлык службаларда да Париж Коммунасының тарихи әһәмияте турында беседалар үткәрәләр.

Революция көрәшчеләренең биографияләрен өйрәнү оештырылды. МОПР почмагы төзелде. Работникларның 92 проценты МОПР членнары.

Г. Садыйков.

СУД

БЕР ВАГОН ЙОМЫРКА

Казан йомырка-кошчылык комбинатында экспедитор булып эшләгән Орлов дигән кешенең эше Киров районының 2 нче участкы халык судында каралганлыгы һәм Орловның 10 елга ябылуга хөкем ителгәнлегә газетабызда язылган иде („Кызыл Татарстан"ның шушы ел, 22 нче февральдә чыккан 43 нче номеры).

Орловның кассация тәртибендә биргән жалобасы буенча бу эш 3 нче мартта Татарстан Верховный Судында тикшерелде. Судка алынган материалларга караганда, Михаил Орлов узган елның 23 нче маенда йомырка-кошчылык комбинатына экспедитор булып кергән. Комбинатның җитәкчеләре аның документларын тикшереп тормаганнар һәм аңа ышанып зур сумалар тапшырганнар. Орлов үз начальникларының гамьсезлегеннән файдаланып, июнь аенда 240 табак ак калайны урлап саткан. Аннары 13 нче июльдә Казан тимер юл станциясенә килгән 15.552 сумлык бер вагон (34.560 данә) йомырканы алып, билгесез кешеләргә саткан да, үзе Семипалатинск шәһәренә качып киткән. Йомырка-кошчылык комбинатының җитәкчеләре аның юкка чыгуы турында милициягә хәбәр итмәгәннәр һәм йомырканың урланганлыгын да белмәгәннәр. Орлов документсыз торган вакытта Семипалатинск шәһәрендә тотылган. Аның янында 5.302 сум акча табылган булган.

Верховный Суд хөкем карарын раслады.

БЕЛДЕРҮЛӘР

10 нчы март, кич 6 сәгатьтә ВКП(б) Өлкә Комитетының Партия Мәгарифе йортында татар телендә лекция була. Тема: „Марксизмның народниклыкка каршы көрәше". Лектор—иптәш Вахитов.

„В. М. МОЛОТОВНЫҢ ЛЕНИНГРАДТАГЫ РЕВОЛЮЦИОН ЭШЕ" ДИГӘН ҖЫЕНТЫК

ЛЕНИНГРАД, 7 март. (ТАСС). Вячеслав Михайлович Молотовның тууына 50 ел тулуга карата Ленинградның партия тарихы институты „В. М. Молотовның Ленинградтагы революцион эше" исемле җыентык чыгара.

Җыентыкта политехника институты студенты Вячеслав Скрябинның яшрен революцион эше, аның үзе тарафыннан төзелгән большевистик студентлар оешмасында, большевистик „Правда" редакциясендә, профсоюзларда эшләве турында, 1916 нчы елның ахрында иптәш Молотовның сөргеннән качканнан соң Петроградка кайтуы турында, большевиклар Үзәк Комитетының Россия бюросында эшләве турында, аннары Октябрь революциясе көннәрендәге эше турында языла.

Ахырдан китапта троцкичылар-зиновьевчылар оппозициясен тар-мар итү өчен ВКП(б) Үзәк Комитетының башка членнары белән берлектә иптәш Молотовның Ленинградка килүе, заводларда һәм партиянең гадәттән тыш конференцияләрендә аның речь сөйләүләре турында языла.

Вахитов исемендәге Жиркомбинатның коллективына

ВКП(б) члены, Сезнең җитәкчегез, Вахитов исемендәге Жиркомбинат директоры Зиннәт Вәли улы Вәлиев иптәшнең вакытсыз үлүе уңае белән ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты һәм Казан Шәһәр Комитеты үзләренең тирән кайгыларын белдерәләр.

Иптәш Вәлиев шәһәрнең партия-җәмагат тормышында актив катнашты, Вахитов исемендәге Жиркомбинат работниклары коллективы һәм шәһәрнең хезмәт ияләре тарафыннан лаеклы рәвештә ышаныч һәм авторитет белән файдаланды, хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советына депутат итеп сайланды. Партиянең Сталин район оешмасы иптәш Вәлиевне ВКП(б) райкомы члены итеп сайлады. Партиянең Казан шәһәр оешмасының V нче конференциясе делегаты итеп һәм партиянең Татарстан Өлкә оешмасының бүген ачыла торган конференциясенә делегат итеп сайланды.

Иптәш Зиннәт Вәли улы Вәлиев, үз постында намус белән эшләп, Ленин—Сталин партиясе эше өчен бөек көрәшкә үзенең бөтен көчен бирде.

Партиянең Татарстан Өлкә Комитеты һәм Казан Шәһәр Комитеты ышаналар ки, Вахитов исемендәге Жиркомбинатның партия оешмасы, эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре коллективы завод эшендә, иптәш Вәлиев эшләгән кебек, югары күрсәткечләр өчен большевикларча көрәшерләр.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

Вахитов исемендәге Жиркомбинат директоры, ВКП (б) члены һәм хезмәт ияләре депутатларының Шәһәр Советы депутаты Зиннәт Вәли улы ВӘЛИЕВНЕҢ вакытсыз үлүе уңае белән ВКП (б) ның Татарстан Өлкә Комитеты һәм Казан Шәһәр Комитеты тирән кайгы белдерәләр һәм мәрхүмнең семьясенең кайгысын уртаклашалар.

ВКП (б) ның Татарстан Өлкә Комитеты.

ВКП (б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

ЯШЕЛЧӘ КУЛЬТУРАЛАРЫНЫҢ ҺӘМ ТАМЫР АЗЫКЛАРНЫҢ СОРТЛЫ ОРЛЫКЛАРЫН „СОРТСЕМОВОЩ" КАЗАН ОРЛЫК БАЗАСЫ МАГАЗИННАРЫННАН ҺӘМ ЛАРЕКЛАРЫННАН АЛЫГЫЗ

Орлыклар хәзер акчага, шулай ук акчаны Дәүләт Банкысы Татарстан Республика конторасында базаның 75030 номеры расчетлар счетына күчерү юлы белән дә сатыла.

Казан орлык базасы магазиннарының һәм ларекларының адреслары: Казанда—Париж Коммунасы урамы, 13/59; Сталин, Молотов районнарындагы базарларда һәм Ягодный бистәсе базарында.

Районнарда—Арча, Балтач, Кукмара, Әгерҗе, Лаеш, Кама Тамагы, Тәтеш, Куйбышев һәм Буа район үзәкләрендә.

Орлыкларның сыйфаты яхшы булуы гарантияләнә.

„Сортсемовощ" ның Казан орлык базасы.

441—1

Бензин һәм майлау материаллары станциясе конторасы
БАРЛЫК АВТОХУҖАЛЫКЛАР ИГЪТИБАРЫНА
БЕЛДЕРӘ.

Татарстан АССР Совнаркомының 1940 нчы ел, 26 нчы февральдә чыгарган 103 нче номерлы карары нигезендә,

автохуҗалыкларны ягулык һәм майлау материаллары белән тәэмин итү һәм аның учеты буенча яңа тәртип кертелә.

Шул уңай белән, автохуҗалыклар кулларында булган барлык талоннарны шәһәрдә 10 нчы мартка кадәр, районнарда 15 нче мартка кадәр, ягулык һәм майлау материаллары станциясенә тапшырырга һәм яңа талоннар алу чарасын күрергә тиешләр. Элекке талоннар шушы ел 1 нче марттан гамәлдән чыккан дип исәпләнә.

Талоннар тапшыручы оешмалар, тапшырылган талоннарга счет язарга тиешләр һәм счетта ул тапшырылган талоннарның бензин һәм майлау материаллары станциясе кассасыннан нинди номерлы счет буенча алынган булуы күрсәтелергә тиеш.

396—3—3

Гражданнар игътибарына!

Бауман район страхование инспекциясе гомерне һәм йорт җиһазларын коллектив һәм индивидуаль страхованиеләү эшләре үткәрә.

Гомерне һәм йорт җиһазларын страхованиеләү өчен—Чернышевский урамы, 9 адресы буенча килергә яисә 38—27 телефоны буенча страхование агентын чакыртырга.

Бауман районы страхинспекциясе.

328—3—1

„Восход" спорт җәмгыяте советы президиумының председателе урынбасары Александр Петрович Петров исеменә бирелгән һәм 1940 нчы ел 5 нче февральдә нотариуста 4531 нче номер белән теркәлгән һәм расланган 5—8 нче номерлы **ышаныч кәгазен,** югалган булу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип санарга.

447—1

СТЗ маркалы мотор куелган
МОТОРЛЫ КӨЙМӘ САТЫЛА

Белешү өчен С. М. Киров исемендәге Казан Химико-Технология институтына килергә. Карл Маркс урамы, 68, бүлмә № 1.

454—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры

12 нче мартта көндез 12 сәгатьтә һәм кич
БИШБҮЛӘК
Талоннар: көндез 132, кич 133.
13 нче мартта
ШӘМСЕКАМӘР
Талон 134.

Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында

Бүген, 10 нчы мартта
ИРЕК
Сезонлы урыннарга 85 нче талоннар белән кертелә.
Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
11 нче мартта ТАССР ның атказанган артисткасы
САРА САДЫЙКОВА КОНЦЕРТЫ
Кич 9 да башлана. Талон 86.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—84 телефоны буенча заявкалар алына.

20 нче март, кич 6 сәгатьтә С. М. Киров исемендәге Казан Химико-Технология институты гыйлми советының ябык утырышы үткәрелә һәм түбәндәге — темаларда —

ДИССЕРТАЦИЯ
яклау үткәрелә:

1. Химик фәннәре кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен, доцент хезмәтләрен үтәүче Г. В. Таһиров. Тема: „Хуш исле аминнар нитрациясенең шартларын өйрәнү".

Рәсми оппонентлар: профессор Л. И. Захаров һәм химик фәннәр кандидаты М. Е. Мойсак.

2. Химик фәннәр кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен, доцент хезмәтләрен үтәүче Л. Т. Водяков. Тема: „Нитроцеллюлозаны стабилизацияләүнең оптималь шартларын эзләп табу".

Рәсми оппонентлар: профессор Г. Х. Камай һәм инженер Корнилов.

453—1 ДИРЕКЦИЯ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 10 нчы мартта
ЛЕНИН
Талон 120.
11 нче мартта кич һәм 12 нче мартта көндез
МАСКАРАД
Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына. Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген, 10 нчы мартта, даимлыклы
ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ
300 хайван һәм кошлар катнаша һәм башка күп — номерлар. —
РСФСР ның атказанган артисты һәм орденлы
М. ЗОЛЛОның
соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.
12 нче мартта зур программа буенча
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы, чит ил фильмы ПЕТЕР
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	КЕЧКЕНӘ АНА
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	ЯШӘРГӘ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	БӘХЕТЛЕ ФИНИШ
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ПАТРИОТ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 268 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 953.